Республика Татарстан
**СОВЕТ
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР
21 нче июль 2021 ел № 8

**2017 елның 19 августындагы 17 номерлы Совет карары белән расланган «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибе һәм «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм башкарма комитет җитәкчесенең контракт буенча вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Ләке авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

2017 елның 19 августындагы 17 номерлы Совет карары белән расланган «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибе һәм «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм башкарма комитет җитәкчесенең контракт буенча вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә 3 нче пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәреш кертергә:

«г)җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча килешүләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә, килешү ясалган акчаларны алу чыганаклары.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Л.И. Шәрипова